ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 2 11.11.2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенә керүче Мачаклы-Баш авылында 2020 елда үзара салым җыюны кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә, "2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Мачаклы-Баш авылында халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең Мачаклы-Баш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
- Мачаклы-Баш авылында бәйрәм чаралары үткәрү (бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, "Җиңү көне", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", "Яңа ел" бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);
Мачаклы-Баш авылында юлларны кардан чистарту;
- Мачаклы-Баш авылында җәй көне территорияне чабу;
- Мачаклы-Баш авылында һәйкәл кую (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);
- Мачаклы-Баш авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясату һәм урнаштыру.
3. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: : http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мачаклы-Баш авылы, Урман ур., 10, Сәпәй авылы, Мәктәп ур. 53В йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Галиева